КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 17 октябрь г.Казань № 2214-б

Халыкара инвалидлар көнен әзерләү һәм үткәрү эшен оештыру, җәмәгатьчелек игътибарын инвалидлар проблемаларына җәлеп итү, аларга ярдәм һәм булышлык күрсәтү максатларында:

1. 2022 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр Татарстан Республикасында, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (алга таба - Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) тәкъдимнәрен үтәп, Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

2022 елның 7 ноябренә кадәр Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планын (алга таба – план) эшләргә, расларга һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне җибәрергә:

2022 елның 7 ноябренә кадәр расланган планны;

2022 елның 16 декабренә кадәр – планны тормышка ашыру турында йомгаклау мәгълүматын.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына 2022 елның 7 ноябренә кадәр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге федераль законны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чараларын күздә тота торган карарларын тормышка ашыру барышу турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү характерындагы аналитик материаллар җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин

итәргә:

мәдәният учреждениеләре тарафыннан «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы» – «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасына, «Хезмәт Кызыл Байрагы ордены Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте» гомумроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк оешмасына, «Менталь һәм башка бозылышлары, үз мәнфәгатьләрен яклауга мохтаҗ булган инвалид балалар һәм 18 яшьтән зуррак инвалидлар ана-аналарының бөтенроссия оешмасы (ВОРДИ)» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенә һәм Татарстан Республикасының башка инвалидлар иҗтимагый берләшмәләренә Халыкара инвалидлар көне уңаеннан Татарстан Республикасының театр-тамаша учреждениеләренә бару өчен чакыру билетлары бирүне;

Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, Халыкара инвалидлар көненә багышланган “Игелеклелек сәнгате” социаль-мәдәни инклюзив акциясен мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә үткәрүне.

5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына инвалид гражданнарга, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтүнең стационар (ярымстационар) оешмаларында бушлай юридик ярдәм күрсәтү эшен оештырырга.

6. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре катнашында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, инвалид булган гражданнарга мәдәни, спорт, ял итү һәм туристлык объектларыннан файдалану мөмкинлеген;

инвалидлар иҗтимагый оешмалары белән берлектә, социаль туризмны үстерү кысаларында тарихи-мәдәни мирас объектларына, спорт, ял итү объектларына экскурсияләр оештыруны.

7. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, яшьләр иҗтимагый оешмалары, инвалидлар иҗтимагый оешмалары белән берлектә:

адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерү өчен шартлар тудыруны тәэмин итәргә;

Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, инвалидлар булган гражданнар катнашында физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәрүне оештырырга.

8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына инвалидлыгы булган яшьләрне һәрьяклап үстерү һәм аның потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруны, яшьләр үзәкләре, яшүсмерләр клублары базасында бушлай инклюзив чаралар уздыруны, шулай ук Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, инвалидлыгы булган яшьләргә социаль ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар үтәүне, яшьләрне актуаль мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итүне һәм аларның позитив гражданлык позициясен формалаштыруны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасында Халыкара инвалидлар көненә багышланган чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара хезмәттәшлеген;

Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча ведомство буйсынуындагы оешмаларда әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чараларны үткәрүне;

2022 елның 22 ноябренә кадәр Халыкара инвалидлар көненә багышланган чараларның республика планын төзүне, шулай ук Татарстан Республикасында инвалидларның социаль-икътисадый хәле һәм аларга дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында мәгълүмат бирү характерындагы аналитик материал әзерләүне;

2022 елның 23 декабренә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планын гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматын җыюны һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Халыкара инвалидлар көненә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

11. Тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә 2022 елның 7 ноябренә кадәр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү характерындагы аналитик белешмә кәгазен җибәрүне;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесенә инвалидларны, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтүнең стационар оешмаларында яшәүчеләрне тернәкләндерүнең техник чаралары һәм шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар белән тәэмин итү өлешендә «Җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында» 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законны, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру барышы хакында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү характерындагы аналитик белешмә кәгазен җибәрүне;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына инвалидларны, инвалид балаларны, шул исәптән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүчеләрне тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча индивидуаль программаларны тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү характерындагы аналитик белешмә кәгазен җибәрүне;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына социаль инклюзияне пропагандалау, җәмәгатьчелекнең инвалид гражданнарга карата хөрмәт белән каравын, төрле өлкәләрдә кеше һәм гражданның барлык гарантияләнгән хокукларын һәм ирекләрен башкалар белән бер тигез тану, тормышка һәм гамәлгә ашыру максатларында төп эшчәнлеге инвалид гражданнарга һәм гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмалар җитәкчеләренә аларның Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар оештыруы һәм үткәрүе турында мәгълүмат җиткәрүне;

Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясенә, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясенә, Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасына, хәйрия фондларына, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларга Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуны;

Татарстан Республикасының сәүдә предприятиеләренә товарларны махсуслаштырып сатуны, инвалид гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ташламалы бәяләргә куллану хезмәтләре күрсәтүне оештыруны.

12. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планын эшләүне, раслауны һәм 2022 елның 7 ноябренә кадәр расланган планны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрүне;

2022 елның 16 декабренә кадәр Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планын тормышка ашыру турында йомгаклау мәгълүматын, шулай ук инвалидлар өчен объектларга керү һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләрен арттыру буенча муниципаль «юл карталарын» тормышка ашыру нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат җибәрүне;

инвалид гражданнарны иҗтимагый структураларга да, муниципаль берәмлекне үстерү процессларына да җәлеп итүгә кагылышлы мөһим мәсьәләләргә ярдәм күрсәтү турында хәбәрдар булуны һәм аны мобилизацияләүне арттыру максатларында, чаралар үткәрү чорында санитария-эпидемиология хәлен исәпкә алып һәм Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, Халыкара инвалидлар көненә багышланган чараларны социаль әһәмиятле акция буларак үткәрүне, шулай ук тормышта авыр хәлдә калган ялгыз инвалидларга, инвалид балалар һәм инвалидлар караучы гаиләләргә аерым игътибар биреп, инвалид гражданнарга социаль-көнкүреш, медицина һәм социаль, психологик һәм башка ярдәм күрсәтүне;

инвалидлар иҗтимагый оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итеп, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларны, ихтыяри катнашучы затларны инвалидларга

ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән хәйрия чараларын һәм акцияләрен әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуга җәлеп итүне;

инвалид гражданнарны эшкә урнаштыру максаты белән махсуслаштырылган вакансияләр ярминкәләрен үткәрүне оештыруда халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә ярдәм күрсәтүне;

Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе киңәшләрен үтәп, муниципаль берәмлекләр территориясендәге оешмалар, предприятиеләр тарафыннан күрсәтелгән оешмаларның, предприятиеләрнең хезмәткәрләре булган (элек эшләгән) инвалидларга, шулай ук инвалидлар яшәгән гаиләләр, инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләр хезмәткәрләренә адреслы ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә;

республика, шәһәр, район инвалидлар оешмалары белән берлектә, ялгыз яшәүче инвалидларның, инвалид балалар һәм инвалидлар карауны гамәлгә ашыручы гаиләләрнең матди-көнкүреш хәлен тикшерүне, алга таба аларга адреслы ярдәм күрсәтүне оештыруны; кирәк булуга карап, Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә урнашкан сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре җитәкчеләре белән инвалидларны шефлык итүне оештыру буенча чаралар күрүне;

инвалидлары, инвалид балалары булган, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм исәптә торган гаиләләрне, сәламәтлекләрен һәм башка игътибарга лаек хәлләрне исәпкә алып, торак белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә игътибарны көчәйтүне.

13. Бу боерыкның 2 – 10 пунктларында күрсәтелгән, Халыкара инвалидлар көненә багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслау 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчеләре буенча каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

14. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин